ГЛАВА УРАХЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422661, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, с.Урахча,
ул.Советская, дом 36а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
УРАКЧА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422661,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы,
Совет урамы, 36а йорт

Тел.: (84361) 29-435 факс: (84361) 29-435, эл.адрес: Urah.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**31.05.2022** **Уракчы авылы** **№ 1**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Урахча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Урахча авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 17.10.2009 ел, №16 карарының 4.4 пункты белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 11 июнендә 09 сәгать 00 минутта Урахча авылында гражданнар Җыенының беренче этабын 29.11.20021 елның 1 номерлы Урахча авылы халкы җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча үткәрүне билгеләргә.
2. 2022 елның 11 июнендә 11 сәгать 00 минутта Урахча авылында гражданнар Җыенының беренче этабын 29.11.20021 елның 1 номерлы Урахча авылы халкы җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча үткәрүне билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Гражданнар җыенында 2011 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә килешәсезме?:

3.1 Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җыелган үзара салым акчалары җибәрелә торган эш төрләре исемлегеннән төшереп калдырырга:

- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү өчен;

«ӘЙЕ» «ЮК».

3.2 Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен үзара салым акчасы җибәрелә торган эш төрләре исемлегенә кертергә.:

- трактор сатып алу өчен.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36а йорты, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Уракчы авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Гәрәев